**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЕРХНЕКАМЕНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
улица Дружба, дом 1а, село Верхняя Каменка,
423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Дружба урамы, 1а йорт, Югары Кәминкә авылы,
423108

тел./факс (84396) 2-31-60/2-34-16 email: Vkam.Cmn2@tatar.ru

№ 1 27 гыйнвар 2023 ел

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 9 августындагы 03-16/5605 номерлы карары нигезендә, авыл җирлеге баш бухгалтерының хезмәт хакын социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 15 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. «Югары Кәминкә авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы нигезләмәнең» 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Баш бухгалтерның вазифа оклады 19700,00 сум (унтугыз мең җиде йөз сум) күләмендә билгеләнә».
2. Әлеге карар нигезендә билгеләнгән хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләме, хезмәткәрләрнең вазифа бурычлары күләмен саклап калу һәм шул ук квалификациядәге эшләрне башкару белән бергә, 2022 елның 31 декабренә түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе М.Н.Минһаҗев